| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СЕЛО-УБЕЙСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>УБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.04.2019 № 52/1

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Үби авыл җирлеге
Советының " Физик затларның
милкенә салым турында
«2014 елның 18 ноябрендәге
46/2 номерлы карарының
2.3 пунктына үзгәрешләр
кертү хакында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 64 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Үби авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Үби авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Үби авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 18.11.2014 ел, № 42/2 карарының 2.3 пунктына (советның 2015 елның 24 апрелендәге 53/2 номерлы, 2015 елның 12 октябрендәге 2/1 номерлы, 2015 елның 18 декабрендәге 4/2 номерлы, 2018 елның 23 августагы № 33/1, 17.12.2018 ел 44/1 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), яңа редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

"Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламаларын бирү турындагы гаризаны үз теләге белән тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.».

2. Бу карарны Үби авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Үби авыл җирлеге башлыгы: Ярухин А.Е.